# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 марта 2017 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (II часть); 2005, № 2, № 4 (I часть), № 6 (II часть), № 11; 2006, № 4, № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 3, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI часть); 2015, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 5, № 6 (I часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (I часть) следующие изменения:

1) в статье 7:

а) пункт 7 части 1 после слов «представительного органа муниципального образования,» дополнить словами «избираемого на муниципальных выборах,»;

б) в части 4 второе предложение изложить в следующей редакции: «Не требуется официальное опубликование (обнародование) порядка учета предложений по проекту муниципального правового акта о внесении изменений и дополнений в устав муниципального образования, а также порядка участия граждан в его обсуждении в случае, когда в устав муниципального образования вносятся изменения в форме точного воспроизведения положений Конституции Российской Федерации, федеральных законов, Конституции Республики Татарстан или законов Республики Татарстан в целях приведения данного устава в соответствие с этими нормативными правовыми актами.»;

в) часть 5 дополнить предложением следующего содержания: «В случае, если глава муниципального образования исполняет полномочия председателя представительного органа муниципального образования, голос главы муниципального образования учитывается при принятии устава муниципального образования, муниципального правового акта о внесении изменений и дополнений в

устав муниципального образования как голос депутата представительного органа муниципального образования.»;

г) дополнить частью 9 следующего содержания:

«9. Приведение устава муниципального образования в соответствие с федеральным законом, законом Республики Татарстан осуществляется в установленный этими законодательными актами срок. В случае, если федеральным законом, законом Республики Татарстан указанный срок не установлен, срок приведения устава муниципального образования в соответствие с федеральным законом, законом Республики Татарстан определяется с учетом даты вступления в силу соответствующего федерального закона, закона Республики Татарстан, необходимости официального опубликования (обнародования) и обсуждения на публичных слушаниях проекта муниципального правового акта о внесении изменений и дополнений в устав муниципального образования, учета предложений граждан по нему, периодичности заседаний представительного органа муниципального образования, сроков государственной регистрации и официального опубликования (обнародования) такого муниципального правового акта и, как правило, не должен превышать шесть месяцев.»;

2) в части 3 статьи 13 слова «карт (планов) объектов землеустройства в орган кадастрового учета в соответствии со статьей 15 Федерального закона от 24 июля 2007 года № 221-ФЗ «О государственном кадастре недвижимости» заменить словами «документов (содержащихся в них сведений) в орган государственного кадастрового учета недвижимого имущества в соответствии со статьей 32 Федерального закона от 13 июля 2015 года № 218-ФЗ «О государственной регистрации недвижимости»;

3) в пункте 11 части 1 статьи 16 слова «организация отдыха детей в каникулярное время» заменить словами «осуществление в пределах своих полномочий мероприятий по обеспечению организации отдыха детей в каникулярное время, включая мероприятия по обеспечению безопасности их жизни и здоровья»;

4) в пункте 13 части 1 статьи 17 слова «организация отдыха детей в каникулярное время» заменить словами «осуществление в пределах своих полномочий мероприятий по обеспечению организации отдыха детей в каникулярное время, включая мероприятия по обеспечению безопасности их жизни и здоровья»;

5) абзац первый части $1^2$ статьи 18 после слов «Законами Республики Татарстан» дополнить словами «в случаях, установленных федеральными законами,»;

6) в абзаце третьем части 4 статьи 21 слова «с правом решающего голоса» исключить;

7) в части 4 статьи 23 слова «с правом решающего голоса» исключить;

8) в статье 24:

а) в пункте 2 части 3 слова «с правом решающего голоса» исключить;

б) в части $3^1$:

в пункте 2 слова «с правом решающего голоса» исключить;

в пункте 3 слова «с правом решающего голоса» исключить;

в) часть 9 изложить в следующей редакции:

«9. В случае досрочного прекращения полномочий главы муниципального образования либо применения к нему по решению суда мер процессуального принуждения в виде заключения под стражу или временного отстранения от должности его полномочия временно исполняет должностное лицо местного самоуправления или депутат представительного органа муниципального образования, определяемые в соответствии с уставом муниципального образования.»;

9) в статье 26:

а) в части 2:

слова «главы администрации» заменить словами «главы местной администрации»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«В случае, предусмотренном абзацем третьим части 4 статьи 21 настоящего Закона, условия контракта в части осуществления полномочий по решению вопросов местного значения для главы местной администрации муниципального района, на которого возлагается исполнение полномочий главы местной администрации поселения, утверждаются представительным органом муниципального района по согласованию с представительным органом такого поселения.»;

б) дополнить частью 9 следующего содержания:

«9. В случае досрочного прекращения полномочий главы местной администрации либо применения к нему по решению суда мер процессуального принуждения в виде заключения под стражу или временного отстранения от должности его полномочия временно исполняет должностное лицо местного самоуправления или уполномоченный муниципальный служащий, определяемые в соответствии с уставом муниципального образования.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
24 марта 2017 года
№ 11-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяда:

а) 1 өлешнең 7 пунктында “муниципаль берәмлекнең” сүзләреннән соң “муниципаль сайлауларда сайлап куела торган” сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлештә икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен тулысынча күчереп, әлеге уставны шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында кертелгән очракта, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (игълан итү) таләп ителми.”;

в) 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкарган очракта, муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт кабул ителгәндә

муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.";

г) түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

"9. Муниципаль берәмлек уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актларында билгеләнгән срокта башкарыла. Әгәр күрсәтелгән срок федераль законда, Татарстан Республикасы законында билгеләнмәгән булса, муниципаль берәмлек уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү срогы тиешле федераль законның, Татарстан Республикасы законының үз көченә керү датасын, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектын рәсми бастырып чыгару (игълан итү) һәм гавами тыңлауларга чыгару, аңа карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу таләп ителүне, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышлары ешлыгын, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәвенә кую һәм рәсми бастырып чыгару (игълан итү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм, кагыйдә буларак, алты айдан күбрәк булмаска тиеш.";

2) 13 статьяның 3 өлешендә "Дәүләт күчемсез милек кадастры турында" 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә җир төзелеше объектларының карталарын (планнарын) кадастр исәбенә алу органнарына" сүзләрен "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында" 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясы нигезендә документларны (алардагы белешмәләрне) күчемсез мөлкәтне дәүләт кадастр исәбенә алу органына" сүзләренә алмаштырырга;

3) 16 статьяның 1 өлешендәге 11 пунктында "каникул вакытында балаларның ялын оештыру" сүзләрен "каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү чараларын, аларның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп, үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыру" сүзләренә алмаштырырга;

4) 17 статьяның 1 өлешендәге 13 пунктында "каникул вакытында балаларның ялын оештыру" сүзләрен "каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү чараларын, аларның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп, үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыру" сүзләренә алмаштырырга;

5) 18 статьяның $1^2$ өлешендәге беренче абзацында "Татарстан Республикасы законнары нигезендә" сүзләре алдыннан "Федераль законнарда билгеләнгән очракларда" сүзләрен өстәргә;

6) 21 статьяның 4 өлешендәге өченче абзацында "хәлиткеч тавыш хокукы белән" сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 23 статьяның 4 өлешендә "хәлиткеч тавыш хокукына ия" сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 24 статьяда:

а) 3 өлешнең 2 пунктында “хәлиткеч тавыш хокукына ия” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) $3^1$ өлештә:

2 пунктта “хәлиткеч тавыш хокукы белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта “хәлиткеч тавыш хокукына ия” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Муниципаль берәмлек башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган йә суд карары буенча аны сак астына алу яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча муниципаль берәмлек уставы нигезендә билгеләнүче җирле үзидарәнең вазыйфаи заты яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты башкара.”;

9) 26 статьяда:

а) 2 өлештә:

“Торак пункт администрациясе башлыгы өчен контракт шартлары торак пунктның” сүзләрен “Җирлекнең җирле администрациясе башлыгы өчен контракт шартлары җирлекнең” сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Әлеге Законның 21 статьясындагы 4 өлешенең өченче абзацында каралган очракта, җирлекнең җирле администрациясе башлыгы вәкаләтләрен башкару йөкләнгән муниципаль район җирле администрациясе башлыгы өчен контрактның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешенә караган шартлары, мондый җирлекнең вәкиллекле органы белән килештереп, муниципаль районның вәкиллекле органы тарафыннан раслана.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

“9. Җирле администрация башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган йә суд карары буенча аны сак астына алу яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча муниципаль берәмлек уставы нигезендә билгеләнүче җирле үзидарәнең вазыйфаи заты яисә вәкаләтле муниципаль хезмәткәр башкара.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2017 ел, 24 март
№ 11-ТРЗ